Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының кырык тугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

5 декабрь, 2024 ел № 374

2023 елда Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) үтәү йомгаклары турында хисап

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 50-51, 85 статьялары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 18 маендагы 238 номерлы «2023-2025 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) үтәү йомгаклары турында хисапны 2023 елда расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Кушымта
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына
5 декабрь, 2024 ел № 374

## 2023 елда Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) үтәү йомгаклары турында хисап

2023 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру «2023-2025 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 18 маендагы 238 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырылды.

Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның төп бурычы муниципаль милек структурасын Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнары вазыйфаларын (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру исәбенә оптимальләштерү.

2023 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына түбәндәгеләр кертелгән:

- 7 күчемле мөлкәт объекты;
- 1 күчемсез мөлкәт объекты;
- «АК БАРС» КОШЧЫЛЫК КОМПЛЕКСЫ» ҖАВАПЛЫЛЫГЫ ЧИКЛӘНГӘН ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ устав капиталындагы өлеше. Җәмгыятьнең устав капиталында өлеш күләме 0,00973% ((ноль бөтен тугыз йөз җитмеш өч йөз мең) процент) тәшкил итә).

Хосусыйлаштыру объектларын сатуның башлангыч бәясе «Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә билгеләнгән базар бәясеннән чыгып билгеләнә.

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетына 1 015 606,00 сум акча керде.